Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы
«Тихоново авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге
гражданнар җыены турында карар

Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының
Тихоново авыл җирлегенең Тихоново авылы торак пунктында
гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

20 ноябрь 2019 ел. № 1

"Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының Тихоново авыл җирлегенең Тихоново авылы торак пунктында гражданнар җыены карар итте:

1. Менделеевск муниципаль районының Тихоново авыл җирлегенең Тихоново авылында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2020 елда 300 сум күләмендә үзара салым акчаларын кертергә, I-II төркем инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышында катнашучылардан тыш, ә күп балалы гаиләләргә-бер тапкыр түләүне киметеп, аны 150 сум итәргә кирәк.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрергә:

1). Су скважинасының коймасын һәм будкасын монтажлау;

2). 3 (5) кВт генератор сатып алу;

3). Триммерлар сатып алу - 2 данә;

4). Тихоново авылы юлларын төзекләндерү һәм чокырларны ямау һәм «ясалма тигезсезлек» җайланмасын төзекләндерү;

5). ЭЦВ-6 су насосы сатып алу.

3. Тихоново авылының мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән гражданнар җыены нәтиҗәләрен игълан итәргә һәм Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында www.mendeleevsk.tatar.ru «Тихоново авыл җирлеге» бүлегендә урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Тихоново авыл җирлеге башлыгы Карманов А.М.